ГЛАВА НОВОИГЛАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНА ИГЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Яңа Иглай авылы **КАРАР**

**«09» ноябрь 2019 ел** **№ 7**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Некрасовка поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Яңа Иглай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Некрасовка торак пунктында Дачная урамы буенча 25 нче йорт янында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2019 елның 27 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Яңа Иглай авыл җирлеге Некрасовка торак пункты территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидыннан тыш, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, ялгыз яшәүче 75тән өлкәнрәк гражданнардан кала 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Некрасовка торак пунктында Дачная урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү)

«ӘЙЕ» «ЮК».

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Некрасовка поселогының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

8. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы Ф.С. Гайнуллин